ГЛАВА АККУЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423744, село Аккузово,
ул.Центральная, д.1

Тел/факс (885552)3-44-42
Akkuz-Akt@yandex.ru

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АККҮЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

423744, Аккүз авылы,
Үзәк ур.,1

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**«26» ноябрь 2019 ел** **№ 34**

**Аккүз авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 25.11.2019 елгы гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә Аккүз авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ**:**

1.Аккүз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 1 төркем инвалидлардан кала, 2020 елда үзара салымның бер тапкыр 700(җиде йөз) сум түләвен кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

* Күмү урыннарын карап тоту:
- Күмү урыннарын документаль рәсмиләштерү;
- зират коймасын ремонтлау;
- ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;
* автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ком-чуерташ Бистәсе, грейдлау, кардан чистарту;)
* җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру
- торак пунктларда су челтәрләрен ремонтлау, тоту, су чыганакларын лицензияләү;
- янгын гидрантларын, янгын краннарын урнаштыру ;
*җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру
- Сабантуй уздыру урыннарын төзекләндерү;
- җирлек торак пунктларында хуҗасыз территорияләрне ремонтлау һәм киртәләү;
- авыл җирлеге территориясендә агач кисү;
- җирлек торак пунктында Игъланнар тактасы ясау һәм аларны урнаштыру;
* урам утларын реконструкцияләү.
- урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту;

2. Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында " Аккүз авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Рәислек итүче: Р.В.Сәхәбетдинов